**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава**
**Тойкинского**
**сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ул. Джалиля, д..19, с.Тойкино,**
**Азнакаевский р-н, РТ 423302**
**Тел.\факс (8-85592) 45089,**

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай**
**муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге**
**башлыгы**

**Җәлил урамы, 19 йорт, Туйкә**
**авылы ,**
**Азнакай районы, ТР 423302**
**Тел. \факс (8-85592) 45089**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

11 ноябрь 2020 ел

№ 14

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 20.04.2012 ел № 36 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына

бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2020 елның 30 ноябрендә 16.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны- Туйкә авыл мәдәният йорты;

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Туйкә авылы, Җәлил урам, 19 йорт.

4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында»гы карар проектын Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru. адресы буенча 2020 елның 11 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Р.Р.Закирова